КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2024 ел, 29 июль

г.Казань

№ 603

Халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору буенча республика ведомствоара комиссиясен төзү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору буенча Россия Федерациясе субъектларының ведомствоара комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2024 елның 3 маендагы 571 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору буенча республика ведомствоара комиссиясен төзергә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору буенча республика ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын;

Халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору буенча республика ведомствоара комиссиясенең эшче төркемнәрен төзү тәртибе һәм аларның эшчәнлеге турындагы нигезләмәне;

Халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору буенча республика ведомствоара комиссиясенең эшче төркемнәре төзелә торган муниципаль берәмлекләр исемлеген.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 29 июль, 603 нче карары белән расланды

# Халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору буенча республика ведомствоара комиссиясен төзү турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору буенча республика ведомствоара комиссиясен (алга таба – Комиссия) төзү тәртибен һәм аның эшчәнлеген билгели.

2. Комиссия республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, контроль-күзәтчелек органнары, җирле үзидарә органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары, шулай ук һөнәри берлекләр, аларның берләшмәләре һәм эш бирүчеләр, аларның берләшмәләре эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү максатларында төзелгән даими эшләүче коллегиаль орган булып тора.

3. Комиссия составына республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча кызыксынучы территориаль органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары, Татарстан Республикасының Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләр төбәк берләшмәсе), «Татарстан Республикасының Һөнәри берлекләр федерациясе» берлеге, «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр Советы» ассоциациясе вәкилләре, Комиссиянең эшче төркемнәре рәисләре, башка кызыксынучы органнар һәм оешмалар вәкилләре керә.

Комиссия утырышларында прокуратура органнары вәкилләренең катнашуы, аның составына кермичә, Комиссия рәисе (рәис урынбасары) чакыруы буенча мөмкин.

4. Комиссия үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

## II. Комиссия эшчәнлеген оештыру нигезләре

5. Комиссия эше утырышлар рәвешендә гамәлгә ашырыла, алар турыдан-туры катнашу форматында яисә видеоконференция элемтәсе форматында үткәрелергә мөмкин.

6. Комиссия составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

Комиссия түбәндәге составта төзелә: Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия әгъзалары һәм Комиссиянең җаваплы секретаре.

Комиссия рәисе аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә һәм Комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җавап бирә.

Комиссия рәисе булмаганда, аның вәкаләтләрен Комиссия рәисе урынбасары гамәлгә ашыра.

Комиссия әгъзалары эш барышында үзләренә мәгълүм булган мәгълүматларны башкаларга таратырга хокуксыз.

Комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен, алыштыру хокукына ия булмыйча, иҗтимагый башлангычларда башкара.

7. Комиссия утырышлары кирәк булуга карап, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә.

Комиссия утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип санала.

Комиссия утырышларын – Комиссия рәисе, ә ул булмаганда Комиссия рәисе урынбасары алып бара.

Комиссия карарлары утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия рәисенең яки аны алыштыручы затның тавышы хәлиткеч була.

Комиссия утырышларын үткәрүне әзерләү һәм оештыру Комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул Комиссия утырышында рәислек итүче тарафыннан имзалана.

9. Комиссиянең үз компетенциясе чикләрендә кабул ителгән карарлары, алар кабул ителгән көннән 5 эш көненнән дә соңга калмыйча, Комиссия әгъзаларына, шулай ук Комиссия утырышларында карап тикшерелгән һәм (яки) тыңланган эш бирүчеләргә җибәрелә.

10. Комиссия карарларының үтәлешен контрольдә тоту Комиссия рәисе (рәис урынбасары) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## III. Комиссиянең бурычлары һәм хокуклары

11. Комиссиянең төп бурычлары:

а) Комиссия вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, контроль-күзәтчелек органнары, җирле үзидарә органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары, һөнәри берлекләр, аларның берләшмәләре һәм эш бирүчеләр, аларның берләшмәләре хезмәттәшлеген координацияләү һәм тәэмин итү;

б) Комиссия һәм Комиссиянең Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль берәмлекләрдәге эшче төркемнәре эше нәтиҗәләрен мониторинглауны һәм анализлауны гамәлгә ашыру;

в) халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору буенча эш нәтиҗәләрен мониторинглауны гамәлгә ашыру.

12. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар кысаларында түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

а) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган Россия Федерациясендә халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору чаралары планында һәм Комиссия тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасында халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору чаралары исемлегендә каралган чараларда катнашуны;

б) төбәк белән идарә итү үзәге, иҗтимагый оешмалар белән гражданнардан һәм юридик затлардан республика башкарма хакимият органнарына, җирле үзидарә органнарына, әлеге органнарның вазыйфаи затларына халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителеше фактлары (билгеләре) турындагы мәгълүмат белән кергән мөрәҗәгатьләрне анализлауны;

в) халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору максатларында контроль (күзәтчелек) чараларын, профилактика чараларын үткәрү өчен булган мәгълүматны федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, республика дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль органнарына җибәрүне;

г) Комиссия һәм Комиссиянең эшче төркемнәре эшләре нәтиҗәләрен анализлауны.

13. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Комиссия утырышларына Комиссия составына керми торган органнарның һәм оешмаларның вазыйфаи затларын һәм белгечләрен (экспертларын) чакырырга һәм тыңларга;

б) Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясындагы 3 өлеше нигезендә исемлеге раслана торган белешмәне һәм мәгълүматны, шул исәптән салым серен тәшкил итә торган мәгълүматны соратып алырга;

в) дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, бюджеттан тыш дәүләт фондларыннан, шәхси мәгълүматларны һәм белешмәләрне кертеп, түбәндәгеләр турында мәгълүмат соратып алырга, шул исәптән:

хуҗалык субъектларының юридик зат яисә индивидуаль эшкуар буларак Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә теркәлүгә алынмыйча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында муниципаль берәмлек территориясендә күчемсез мөлкәт объектларыннан файдалануы турында;

хезмәт законнары нигезендә хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштермичә гражданнарның хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге турында һәм (яисә) хезмәткәр белән эш бирүче арасында хезмәт мөнәсәбәтләрен фактта җайга сала торган гражданлык-хокукый шартнамәләр төзү мөмкинлеге турында;

хуҗалык субъектларының Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә лицензияләнергә тиешле эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруы турында;

чараларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) гамәлгә ашыру өчен бюджеттан дәүләт ярдәме күрсәтелгән хуҗалык субъектлары турында мәгълүмат булу хакында;

төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактлары буенча күрсәтелә торган хезмәтләр күләме (кеше-сәгать, хезмәт күрсәтү нормалары) хисаплылыкта күрсәтелгән хезмәткәрләр санына туры килми торган хуҗалык субъектлары турында мәгълүмат булу хакында;

г) Комиссия утырышларында түбәндәгеләргә бәйле хәлләрне карап тикшерергә:

хезмәт законнарында билгеләнгән хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштерү тәртибен бозып, хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруга;

әлеге чор өчен эш вакыты нормасын тулысынча эшләгән һәм хезмәт нормасын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән хезмәткәрләргә айлык хезмәт хакын хезмәт өчен түләүнең тиешле минималь күләменнән (минималь хезмәт хакы күләменнән) түбәнрәк түләү буенча билгеләнгән фактлар булуга;

хезмәт мөнәсәбәтләрен гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләр белән (шул исәптән «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар белән үзара хезмәттәшлек иткәндә) алмаштыруга;

д) массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнарга халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенең тискәре нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирүне гамәлгә ашырырга;

е) халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителеше билгеләренә ия хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру фактлары буенча шикаятьләрен кабул итү һәм мондый шикаятьләргә карата оператив чара күрү буенча «кайнар линия» оештырырга.

14. Халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору максатларында контроль (күзәтчелек) чараларын, профилактика чараларын үткәрү өчен федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, республика дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль органнарына рәсми сораулар җибәрү, тиешле мәгълүмат әзерләү, мәгълүмат җибәрү түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырыла:

а) эшне оештыру кысаларында Комиссиянең рәсми сораулары, шул исәптән Комиссиянең эшче төркемнәре өчен кирәкле мәгълүмат һәм белешмә алу өчен рәсми сораулар рәсми бланкларда рәсмиләштерелә һәм аларга Комиссия рәисе яисә аның урынбасары тарафыннан, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып, электрон рәвештә кул куела;

б) органнар һәм оешмалар тарафыннан Комиссиянең кирәкле материаллар һәм мәгълүмат тапшыру турындагы рәсми сорауларын карап тикшерү срогы Комиссиянең тиешле рәсми соравын теркәүгә алган көннән 15 календарь көннән артмаска тиеш;

в) халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору максатларында контроль (күзәтчелек) чаралар, профилактик чаралар үткәрү өчен республика дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль органнарына мәгълүмат җибәрү Комиссия утырышларының беркетмә карарлары рәвешендә рәсмиләштерелә.

15. Комиссия:

а) халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору мәсьәләләре буенча республика контроль (күзәтчелек) органнары тәкъдимнәрен карап тикшерә;

б) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда һәм тәртиптә дәүләт мәгълүмат системаларыннан файдалана;

в) Комиссиянең аерылгысыз өлеше була торган эшче төркемнәр төзи;

г) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында Комиссия эше турында актуаль мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итә.

16. Комиссиядә хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштерү тәртибен бозу һәм әлеге чор өчен эш вакыты нормасын тулысынча эшләгән һәм хезмәт нормасын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән хезмәткәрләргә айлык хезмәт хакын хезмәт өчен түләүнең тиешле минималь күләменнән (минималь хезмәт хакы күләменнән) түбән түләү буенча ачыкланган фактлар булу турында мәгълүмат булганда, Комиссия контроль (күзәтчелек) чараларын уздыру турындагы мәсьәләне карап тикшерү өчен Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясенә тиешле мәгълүмат җибәрә.

_______________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 29 июль, 603 нче карары белән расланды

Халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору буенча республика ведомствоара комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, комиссия рәисе |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры, комиссия рәисе урынбасары |
| Вәлиуллов Рөстәм Фәйзрахман улы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары, комиссиянең җаваплы секретаре |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Гревцов Андрей Борисович | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасары |
| Дмитриев Виктор Петрович | Татарстан Республикасының Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләр төбәк берләшмәсе) генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Зәйнетдинова Алсу Хәмит кызы | Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы – Татарстан Республикасында баш дәүләт хезмәт инспекторы (килешү буенча) |
| Кузьмичева Елена Ивановна | «Татарстан Республикасының Һөнәр берлекләре федерациясе» берлеге рәисе (килешү буенча) |
| Нәбиуллина Лилия Мөхәммәтовна | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Олейник Павел Михайлович | Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе җитәкчесенең беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Пелевин Олег Владимирович | Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары |
| Сабурская Алина Викторовна | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы |
| Семенычев Аркадий Борисович | «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе башкарма секретаре (килешү буенча) |
| Тарасова Надежда Валентиновна | Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Хисмәтуллин Илсур Хәйдәр улы | Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| | Халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору буенча республика ведомствоара комиссиясенең эшче төркемнәр рәисләре (килешү буенча). |

___________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 29 июль, 603 нче карары белән расланды

Халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору буенча республика ведомствоара комиссиясенең эшче төркемнәрен төзү тәртибе һәм аларның эшчәнлеге турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору буенча республика ведомствоара комиссиясенең эшче төркемнәрен (алга таба – эшче төркем) төзү тәртибен һәм аның эшчәнлеген билгели.

2. Эшче төркемнәр муниципаль берәмлек территориясендә җирле үзидарә органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль бүлекчәләре, контроль-күзәтчелек органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары, шулай ук һөнәри берлекләр, аларның берләшмәләре һәм эш бирүчеләр, аларның берләшмәләре эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү максатларында төзелгән даими эшләүче коллегиаль органнар булып тора.

3. Эшче төркемнәр составына җирле үзидарә органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча кызыксынучы территориаль бүлекчәләре, бюджеттан тыш дәүләт фондлары (килешү буенча), эш бирүчеләр берләшмәләре (килешү буенча), һөнәри берлекләр берләшмәләре (килешү буенча) вәкилләре, башка кызыксынучы органнар һәм оешмалар вәкилләре (килешү буенча) керә.

Эшче төркем утырышларында прокуратура органнары вәкилләренең катнашуы, аның составына кермичә, эшче төркем рәисе (рәис урынбасары) чакыруы буенча мөмкин.

4. Эшче төркемнәр үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнар, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президентының, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

## II. Эшче төркем эшчәнлеген оештыру нигезләре

5. Эшче төркем эшчәнлеге утырышлар рәвешендә гамәлгә ашырыла, алар турыдан-туры катнашу форматында яисә видеоконференция элемтәсе форматында үткәрелергә мөмкин.

6. Эшче төркем составы Халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан раслана.

Эшче төркем түбәндәге составта төзелә: эшче төркем рәисе, эшче төркем рәисе

урынбасары, эшче төркем әгъзалары һәм эшче төркем секретаре.

Эшче төркем рәисе аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә һәм эшче төркемгә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җавап бирә.

Эшче төркем рәисе булмаган очракта, аның вәкаләтләрен эшче төркем рәисе урынбасары башкара.

Эшче төркем әгъзалары эш барышында үзләренә мәгълүм булган мәгълүматларны башкаларга таратырга хокуксыз.

7. Эшче төркем утырышлары кирәк булуга карап, әмма айга кимендә бер тапкыр үткәрелә.

Эшче төркем утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип санала.

Эшче төркем утырышларын – эшче төркем рәисе, ә ул булмаганда эшче төркем рәисе урынбасары алып бара.

Комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен, алыштыру хокукына ия булмыйча, иҗтимагый башлангычларда башкара.

Эшче төркем карарлары утырышта катнашучы эшче төркем әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, эшче төркем рәисенең яки аны алыштыручы затның тавышы хәлиткеч була.

Эшче төркем утырышларын үткәрүне әзерләү һәм оештыру эшче төркем секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Эшче төркем карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа утырышта рәислек итүче тарафыннан кул куела.

9. Эшче төркемнең үз компетенциясе чикләрендә кабул ителгән карарлары, кабул ителгән көннән 5 эш көненнән дә соңга калмыйча, эшче төркем әгъзаларына, эш бирүчеләргә, утырышта карап тикшерелгән һәм (яисә) тыңланган эш бирүчеләргә, шулай ук Халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору буенча республика ведомствоара комиссиясенә җибәрелә.

10. Эшче төркем карарларының үтәлешен контрольдә тоту эшче төркем рәисе (рәис урынбасары) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## III. Эшче төркемнең бурычлары һәм хокуклары

11. Эшче төркемнең төп бурычлары:

а) эшче төркем вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында җирле үзидарә органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының һәм контроль-күзәтчелек органнарының үзара хезмәттәшлеген координацияләү һәм тәэмин итү;

б) эшче төркем эшчәнлеген мониторинглауны гамәлгә ашыру;

в) халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору буенча эш нәтиҗәләрен мониторинглауны гамәлгә ашыру.

12. Эшче төркем үзенә йөкләнгән бурычлар кысаларында түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

а) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган Россия Федерациясендә халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору чаралары планында һәм Комиссия тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасында халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору чаралары исемлегендә каралган чараларда катнашуны;

б) гражданнардан һәм юридик затлардан җирле үзидарә органнарына, әлеге

органнарның вазыйфаи затларына халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителеше фактлары (билгеләре) турында мәгълүмат белән кергән мөрәҗәгатьләрне анализлауны;

в) эшче төркем эшчәнлеге нәтиҗәләрен анализлауны.

13. Эшче төркем түбәндәгеләргә хокуклы:

а) эшче төркем утырышларына эшче төркем составына керми торган органнарның һәм оешмаларның вазыйфаи затларын һәм белгечләрен (экспертларын) чакырырга һәм тыңларга;

б) Комиссия аша түбәндәгеләрдән соратып алырга:

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Федераль законның 67 статьясындагы 3 өлеше нигезендә исемлеге раслана торган белешмәне һәм мәгълүматны, шул исәптән салым серен тәшкил итә торган мәгълүматны Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән;

түбәндәге мәгълүматны (персональ мәгълүматларны һәм белешмәләрне кертеп) җирле үзидарә органнарыннан, бюджеттан тыш дәүләт фондларының территориаль бүлекчәләреннән, шул исәптән:

хуҗалык субъектларының юридик зат яисә индивидуаль эшкуар буларак Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә теркәлүгә алынмыйча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында муниципаль берәмлек территориясендә күчемсез мөлкәт объектларыннан файдалануы турында;

хезмәт законнары нигезендә хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштермичә гражданнарның хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге турында һәм (яисә) хезмәткәр белән эш бирүче арасында хезмәт мөнәсәбәтләрен фактта җайга сала торган гражданлык-хокукый шартнамәләр төзү мөмкинлеге турында;

хуҗалык субъектларының Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә лицензияләнергә тиешле эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруы турында;

чараларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) гамәлгә ашыру өчен бюджеттан дәүләт ярдәме күрсәтелгән хуҗалык субъектлары турында мәгълүмат булу хакында;

төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактлары буенча күрсәтелә торган хезмәтләр күләме (кеше-сәгать, хезмәт күрсәтү нормалары) хисаплылыкта күрсәтелгән хезмәткәрләр санына туры килми торган хуҗалык субъектлары турында мәгълүмат булу хакында;

в) эшче төркем утырышларында түбәндәгеләргә бәйле хәлләрне карап тикшерергә:

хезмәт законнарында билгеләнгән хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштерү тәртибен бозып, хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруга;

әлеге чор өчен эш вакыты нормасын тулысынча эшләгән һәм хезмәт нормасын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән хезмәткәрләргә айлык хезмәт хакын хезмәт өчен түләүнең тиешле минималь күләменнән (минималь хезмәт хакы күләменнән) түбәнрәк түләү буенча билгеләнгән фактлар булуга;

хезмәт мөнәсәбәтләрен гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләр белән (шул исәптән «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар белән үзара хезмәттәшлек иткәндә) алмаштыруга;

г) массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнарга халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенең тискәре нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыруга.____________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 29 июль, 603 нче карары белән расланды

Халыкның легаль булмаган эш белән тәэмин ителешенә каршы тору буенча республика ведомствоара комиссиясенең эшче төркемнәре төзелә торган муниципаль берәмлекләр исемлеге

1. Әгерҗе муниципаль районы
2. Азнакай муниципаль районы
3. Аксубай муниципаль районы
4. Актаныш муниципаль районы
5. Алексеевск муниципаль районы
6. Әлки муниципаль районы
7. Әлмәт муниципаль районы
8. Апас муниципаль районы
9. Арча муниципаль районы
10. Әтнә муниципаль районы
11. Баулы муниципаль районы
12. Балтач муниципаль районы
13. Бөгелмә муниципаль районы
14. Буа муниципаль районы
15. Югары Ослан муниципаль районы
16. Биектау муниципаль районы
17. Чүпрәле муниципаль районы
18. Алабуга муниципаль районы
19. Зәй муниципаль районы
20. Зеленодольск муниципаль районы
21. Кайбыч муниципаль районы
22. Кама Тамагы муниципаль районы
23. Кукмара муниципаль районы
24. Лаеш муниципаль районы
25. Лениногорск муниципаль районы
26. Мамадыш муниципаль районы
27. Менделеевск муниципаль районы
28. Минзәлә муниципаль районы
29. Мөслим муниципаль районы
30. Түбән Кама муниципаль районы
31. Яңа Чишмә муниципаль районы
32. Нурлат муниципаль районы
33. Питрәч муниципаль районы
34. Балык Бистәсе муниципаль районы

35. Саба муниципаль районы
36. Сарман муниципаль районы
37. Спас муниципаль районы
38. Тәтеш муниципаль районы
39. Тукай муниципаль районы
40. Теләче муниципаль районы
41. Чирмешән муниципаль районы
42. Чистай муниципаль районы
43. Ютазы муниципаль районы
44. Казан шәһәре
45. Яр Чаллы шәһәре.